КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 декабрь г.Казань № 1291

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 3 апрель, 146 нчы; 2007 ел, 7 ноябрь, 607 нче; 2009 ел, 30 гыйнвар, 45 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 8 июль, 472 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 890 нчы; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче, 2019 ел, 13 сентябрь, 832 нче, 2020 ел, 9 июнь, 476 нчы, 2021 ел, 23 апрель, 277 нче, 2022 ел, 4 июль, 620 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның беренче абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүгә» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның җиденче абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүгә» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның алтынчы абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүгә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү

тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2018 ел, 12 декабрь, 1117 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 26 сентябрь, 877 нче; 2020 ел, 12 июнь, 485 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче, 2022 ел, 18 гыйнвар, 21 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктның 2.2.1 пунктчасындагы тугызынчы абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүгә» сүзләренә алмаштырырга.;

2.4 пунктның сигезенче абзацында «салымнар, җыемнар» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүгә» сүзләренә алмаштырырг;

3.5 пунктның тугызынчы абзацында «салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр» сүзләрен «салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләүгә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин